**Ачык сервитут билгеләү мөмкинлеге турында хәбәр**

Кукмара муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы 16:23:090702 кадастр кварталында дәүләт милке чикләнмәгән җирләргә карата газ белән тәэмин итү системасының линия объектларын һәм аларның «Кукмара районы, Зур Сәрдек торак пункты, Май ур., 16 йорт адресында 43 нче ГРП ны техник яктан яңадан үзгәртеп кору» аерылгысыз технологик өлешләрен төзү максатларында гавами сервитут булдыру мөмкинлеге турында хәбәр итә. Ачык сервитут билгеләү планлаштырыла торган күрсәтелгән җирләрнең бер өлеше мәйданы: 26 кв. м;

Территориаль планлаштыру документын раслау турындагы карарның реквизитлары: Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районын территориаль планлаштыру схемасын раслау турында» 2012 елның 19 декабрендәге 171 номерлы карары.

Табигый монополияләр субъектлары программасын раслау турындагы карарның реквизитлары: 2024 – 2030 елларга «Газпром трансгаз Казан» ҖЧҖ ЭПУ буенча газны редукцияләү пунктларын реконструкцияләү программасы

Кызыксынган затлар гавами сервитут билгеләү турында кергән үтенечнамә һәм аңа кушымта итеп бирелә торган гавами сервитут чикләре урнашкан урын тасвирламасы белән таныша ала, РФ Җир кодексының 39.42 статьясындагы 8 пунктында каралган вакыт эчендә җирләр кишәрлекләренә хокукларны исәпкә алу турында гаризаларны Кукмара муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына тапшыра алалар, адресы: Татарстан Республикасы, Кукмара шәһәре, Эшчеләр тыкрыгы ур., 7 нче йорт (Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе» бинасы; беренче кат), эш көннәрендә 8:30 дан 15:00 гә кадәр (төшке аш 12:00 дән 13:00 гә кадәр). Җир кишәрлекләренә хокукларны исәпкә алу турында гаризаларны һәм башка документларны почта аша җибәрү өчен почта адресы: 422110, Татарстан Республикасы, Кукмара ш., Ленин ур., 15.

Әлеге хәбәр урнаштырыла торган рәсми сайтлар:

- https://pravo.tatarstan.ru ;
- http://kukmor.tatarstan.ru.